ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**10.01.2018 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 15**

2018 елга Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларына норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 21 декабрендәге 1879 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елга түбәндәге кушымтада бирелгәнне расларга:
Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәбендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны.
2. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ мәгариф оешмаларын финанслауны 2017 елның 22 сентябрендәге «2018 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук естәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына туры китереп тәэмин итәргә; әлеге карарның 1 пункты.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.В.Афанасьевага йөкләргә .

ЗМР БК җитәкчесе вазифаларын башкаручы А. В. Старостин

Расланган
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 10 гыйварындагы
15 номерлы карары белән

**Зеленодольск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат мәктәбендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, бер елга сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 86883 |
| | авыл җирлеге | 88242 |
| Гомуми белем бирү интернат мәктәбе | шәһәр җирлеге | 132229 |
| | авыл җирлеге | 136695 |